# КИТАПХАНӘ

НАЦИОНАЛЬНАЯ БИБЛИОТЕКА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МИЛЛИ КИТАПХАНӘСЕ

НАУЧНО-ПРАКТИЧЕСКИЙ ЖУРНАЛ
ФӘННИ-ГАМӘЛИ ЖУРНАЛ

1 53
2022





Рәисә САЛИХОВА,
*Татарстан Республикасы*
*Яр Чаллы шәһәре Үзәк китапханәсенең*
*автоматлаштыру*
*бүлеге җитәкчесе*

# Телекүпер Чаллы һәм Финляндия яшьләрен берләштерде


1



2

1-2
На прямую связь с читателями вышел доктор философских наук Финляндии Рамиль хазрат Беляев

Укучылар белән туры элемтәгә Финляндиянең фәлсәфә фәннәре докторы Рамил хәзрәт Беляев чыкты

Яр Чаллы шәһәренең Муса Җәлил исемендәге Үзәк китапханәсе «Китап укучы яшьләр – милләтнең киләчәге» дип аталган проект кысаларында Чаллы һәм Финляндиянең татар яшьләре арасында онлайн-телекүпер оештырды. Әлеге чара Үзәк китапханә Татарстан Республикасының телләр күптөрлелеген саклауга юнәлдерелгән проектларны һәм чараларны гамәлгә ашыруда муниципаль мәдәният учреждениеләренә ярдәм итү юнәлешендә откан грант хисабына үтте.

Әлеге проект мәдәниятара иҗади диалогны үстерү, татар телен өйрәнү һәм куллану, Татарстан һәм Финляндия җирлегендә яшәүче яшьләр арасында туган телне һәм гореф-гадәтләрне саклап калу белән бәйле проблемаларны ачыклау һәм хәл итү өчен ачык киңлек булдыруны күздә тотты.

18–30 яшьлек татар яшьләре арасында уздырылган «Мәдәни урталыкны саклау ысулы буларак туган телдә (татар телендә) аралашуга ихтыяҗ» дигән тикшеренү нәтиҗәләре проектны тормышка ашыруда нигез булып торды.

Шуны әйтергә кирәк: китапханәдә туган телне, туган якны өйрәнүгә зур игътибар бирелә.

Төрле фестивальләр, бәйгеләр, онлайн-кичәләр, каләм тибрәтүчеләр белән иҗади очрашулар даими үткәрелеп тора. Китап укучылар белән турыдан-туры элемтәгә Финляндиядән философия фәннәре докторы, махсус китаплар сериясе, ислам дине һәм татар тарихы турында күпсанлы мәкаләләр авторы Рамил хәзрәт Беляев чыкты.

Ул татар диаспорасы тормышы, Финляндиядә 130 ел дәвамында татарларның дин, тел һәм мәдәниятне саклау ысуллары хакында җентекләп сөйләде һәм әлеге темага презентация тәкъдим итте. Анда яшәүче милләттәшләребез балаларын туган телгә һәм дин нигезләренә өйрәтә, китаплар нәшер итү белән шөгыльләнә, башка илләрдәге татар җәмгыятьләре белән тыгыз элемтәдә тора.

Экран аша Рамил Беляев Скандинавия илендә яшәүче татарларның тарихы һәм язмышы турында үзенең «Финляндия татарлары» китабын тәкъдим итте. Автор китапка элек беркайда да басылмаган архив документлары, фоторәсемнәр кертелүе турында сөйләде. Басманың бер өлеше Финляндия татарларының туган телен һәм динен саклап калуга багышланган.

Очрашуда Чаллы педагогия университеты студентлары, шәһәр язучылары катнашты. Алар Рамил Беляевка үз сорауларын җиткерде.




1
Обложка книги Рамиля Беляева «Татары Финляндии»

Рамил Беляевның «Финляндия татарлары» китабы тышлыгы

2
Поддержка Военного министерства давала возможность развития религиозной жизни военных татар в Финляндии

Хәрби министрлыкның ярдәме Финляндиядәге хәрби татарларның дини тормышы үсешенә юл ачкан


3
После Первой мировой войны финские татары вернулись к предпринимательской деятельности

Беренче бөтендөнья сугышыннан соң Финляндия татарлары кабаттан эшкуарлыкка кайта










4
Центр г.Котка. 1930 год

Котка шәһәре үзәге. 1930 ел

5
Татарский этнопласт сформировался из татар-коммерсантов

Татар этнопласты татар сәүдәгәрләреннән формалашкан

6
Для татар Финляндии чрезвычайно важным являлись семейно-родственные связи

Финляндия татарлары өчен гаилә-туганлык мөнәсәбәтләре аеруча мөһим булган



Праздник имянаречения в Куопио. 1926 год.

Куопиода балага исем кушу бәйрәме. 1926 ел.

«Көмеш кыңгырау» журналисты Ләйлә Мирзаһитованың «Финляндиядә татар балалары татар телен ничек, кайда өйрәнә?» дигән соравына ул: «Татар телен балалар атнага бер тапкыр өйрәнә. Бу бик аз, әлбәттә. Телне саклауның төп чарасы – ул гаиләдә аралашу», – дип җавап бирде. Шулай ук телекүпер барышында Финляндия татарларыннан музыкаль күчтәнәч – татар халык җыры «Ай, былбылым» – яңгырады.

Финляндиядә елына ике тапкыр «Мәхәллә хәбәрләре» дигән журнал чыга. Ул халыкка почта аша таратыла. Анда, яңалыклар белән беррәттән, төрле әдәби әсәрләр, шигырьләр дә бастырыла. Шулай ук дини һәм балалар өчен сәхифәләр дә бар.

Рамил Беляев үзенең ютуб-каналында «Ачык сөйләшү» проектын алып баруы хакында да искәртеп үтте. Айга бер тапкыр үтүче чарада татар телендә төрле темаларга сөйләшү оештырылуы турында әйтте.

Педагогия университеты студентларын шулай ук фин гаиләләрендә нинди телдә сөйләшүләре, фин халкының милли бәйрәмнәре һәм башка төрле сораулар кызыксындырды. Рамил әфәнде барысына да төгәл җаваплар биреп, кунакларга Финляндиядән тагын бер музыкаль күчтәнәч ирештерде.

Яшьләр телекүпере, татар халкының бай мәдәни, рухи һәм тел традицияләрен популярлаштыру өчен ачык онлайн-киңлек булып, Татарстан һәм Финляндия татарлары арасында элемтәләрне ныгытырга ярдәм итте. Телекүпер барышында катнашучылар татар телендә аралашу, китап уку, милли бәйрәмнәр һәм гореф-гадәтләр, телне саклау буенча заманча аралашу чаралары турында фикер алыштылар.

Проект яшьләрнең татар телендә сөйләшү һәм укуга карата кызыксынуларын үстерергә, татар телендә дөньякүләм аралашып булуын күрсәтергә мөмкинлек бирде. ❖

**РУС.** | В Центральной городской библиотеке Набережных Челнов состоялся телемост «Читающая молодёжь – будущее нации», в котором приняли участие молодые жители автограда и татарская молодёжь Финляндии. Также участниками этой видеовстречи стали студенты Челнинского педагогического университета и писатели. В ходе телемоста участники говорили о путях сохранения традиций и культурной идентичности татарского народа, чтении книг и общении на родном языке. На прямую связь с читателями вышел доктор философских наук Финляндии Рамиль хазрат Беляев, который в рамках встречи презентовал свою книгу «Татары Финляндии», рассказывающую об истории и судьбе татар, живущих в этой скандинавской стране.